ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАДЫБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАДЫБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 Кадыбаш авылы 5

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципа районының Кадыбаш авыл җирлеген гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау уздыру тәртибен раслау турында» Татарст Республикасы Әгерҗе муниципаль райо Кадыбаш авыл җирлеге Башкарма комитетын 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карары үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 2, 3 өлешләре нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокурорының «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өлкәсендә законнарны бозуларны бетерү турында» 2021 елның 11 декабрендәге 02-08-02-2021/277 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегендә гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштыру тәртибендә халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Х.Л.Закиров

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш
авыл җирлеге башкарма комитеты
карары белән расланган

**1«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегендә гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлегенең башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибендә:

1) 4 пунктында:

«Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерә» сүзләреннән соң «һәм хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи» сүзләрен өстәргә.»;

2) 6 пунктында:

«елга ике тапкыр» сүзләреннән соң «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 санына кадәр» сүзләрен өстәргә.